Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Ширәмәт пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 15 ноябре № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлегенең Ширәмәт пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Ширәмәт пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 200 сум күләмендә 2019 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен тотырга (төзекләндерү һәм тренажерлар алу өчен)

Гражданнар җыенында рәислек итүче В.Г. Емельянов

Ширәмәт авыл җирлеге башлыгы В.Г. Емельянов